**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей 3[1] Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территориях следующих населенных пунктов Республики Татарстан:

деревня Тангачи Лаишевского района;

деревня Новые Зюри Тюлячинского района;

б) на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

улица Мартынова в селе Билярск Алексеевского района;

улица Лесная в поселке Озерный Высокогорского района;

улица Ленина в поселке городского типа Богатые Сабы Сабинского района;

улица Заречная в селе Большие Метески Тюлячинского района;

территория, используемая филиалом общества с ограниченной ответственностью «Сэт Иле» – «Аксу» (отделение Мюд, бригада № 2) для содержания крупного рогатого скота, у села Старое Мокшино Аксубаевского района.

2. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 13 июля 2015 года № УП-636 «Об установлении карантина на территории деревни Тангачи Лаишевского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 13 июля 2015 года № УП-637 «Об установлении карантина на территории деревни Новые Зюри

Тюлячинского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
15 сентября 2015 года
№ УП-868

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Лаеш районының Тамгачы авылы;

Теләче районының Яңа Җөри авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Биләр авылындагы Мартынов урамы;

Биектау районының Күлле поселогындагы Урман урамы;

Саба районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогының Ленин урамы;

Теләче районының Олы Мәтәскә авылындагы Елга аръягы урамы;

Аксубай районының Иске Мукшы авылы янындагы, «Сөт Иле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Аксу» филиалы (Мюд бүлекчәсе, 2 нче бригада) тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территория.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Лаеш районының Тамгачы авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге ПУ-636 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Теләче районының Яңа Җөри авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы

булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге ПУ-637 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 15 сентябрь
№ ПУ-868